**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1209**
**20.02.2021**

Башкарма комитетның «2015-2023 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 7047 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Законы, шәһәр Уставының 53 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2015-2023 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 7047 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2014 елның 8 декабрендәге 7609 номерлы, 2016 елның 30 мартындагы 1423 номерлы, 2016 елның 20 маендагы 2539 номерлы, 2018 елның 12 мартындагы 1243 номерлы, 2018 елның 6 сентябрендәге 4995 номерлы, 2019 елның 29 мартындагы 1613 номерлы, 2019 елның 16 сентябрендәге 4704 номерлы, 2020 елның 13 августындагы 3930 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2015-2023 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын финанслауны шәһәр бюджетының «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13 һәм «Яшьләр сәясәте һәм балаларны сәламәтләндерү» 07.07 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына 971,8 мең сум күләмендә тәэмин итәргә, шул исәптән: 2015 ел – 20 мең сум, 2016 ел – 120,00 мең сум, 2017 ел – 120,00 мең сум, 2018 ел – 111,8 мең сум, 2019 ел – 120,00 мең сум, 2020 ел – 119,95 мең сум, 2021 ел – 120,00 мең сум, 2022 ел – 120,00 мең сум, 2023 ел – 120,00 мең сум.»;

2) «2015-2023 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганак лары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум) |
| | Муниципаль бюджет | 20 | 120,00 | 120,00 | 111,8 | 120,00 | 119,95 | 120,00 | 120,00 | 120,00 | 971,75 |
| | Республика бюджеты | | | | | | | | | | |
| | Федераль бюджет | | | | | | | | | | |
| | Башка чыганаклар | | | | | | | | | | |
| | Барлыгы | 20 | 120,00 | 120,00 | 111,8 | 120,00 | 119,95 | 120,00 | 120,00 | 120,00 | 971,75 |
| | | Искәрмә: финанслау күләмнәре прогноз характерына ия һәм Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. | | | | | | | | | |

- 4 бүлектә:

4 пунктның 34.3 пунктчасындагы 12 баганада «33» цифрын «32,95» цифрына алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов